| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 31 гыйнвары № 1

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җеназа эшләре турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җеназа эшләре турында Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 30 гыйнварындагы «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 119 номерлы карары белән, Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итә:**

1. 1 нче кушымтага һәм 2 нче кушымтага ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы рәвештә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 7 793,48 суммасында билгеләргә һәм 2023 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 2 нче номерлы карарын 2023 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Олы Ачасыр авыл жирлеге
башлыгы урынбасары М.Г. Гатиятуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Олы Ачасыр авыл жирлеге башкарма
комитетының 2023 елның
31 гыйнварындагы 1 нче номерлы
карарына1 нче кушымта

**2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл жирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 4 247,07 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (мәетне) зиратка илтү | 1 209,84 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 336,57 |
| **Барлыгы** | **7 793,48** |

Зеленодольск муниципаль районы
Олы Ачасыр авыл жирлеге башкарма
комитетының 2023 елның
31 гыйнварындагы 1 нче номерлы
карарына 2 нче кушымта

**2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл жирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Гәүдәне гыйбадәтләү | 750,35 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 3 496,72 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (мәетне) зиратка илтү | 1 209,84 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 336,57 |
| **Барлыгы** | **7 793,48** |